# Хаҗиәхмәт нәселе бәйрәме

15 ел элек мәктәптә «Башкортстан тарихы» фәне укытыла башлады. Мин ул чакта Караяр мәктәбенең 7нче классында укый идем. Берчак үз гаиләңнең нәселен төзергә дип өйгә эш бирделәр. Картыйлар һәм картәти ярдәме белән мин үземнең шәҗәрә агачымны төзедем, анда 100гә якын исем бар иде.



Мин инде күптән Караярда яшәмим. Туган ягыма чираттагы ялга кайтканда, республикабыздагы яңалыкны – шәҗәрә бәйрәмнәре үткәрелүен күреп миндә кызыксыну туды.

Хәзер исә унбиш ел элек төзелгән минем шәҗәрәмдә кимендә 500ләп исем җитми иде...

Туганнар көче белән бергәләп төзелгән шәҗәрә әниемнең агасының (Хәнәфи картәтинең өлкән абыйсы) язмаларына нигезләнгән иде. Безнең шәҗәрә агачы Хаҗиәхмәт карт-карт-картәтидән башлана, аның алты улы булган, аларның балалары, ә балаларының оныклары һәм туруннары булган, улым белән мин дә шуларга керәм. Нәсел агачы төзү һәм бизәү күп көч таләп итте, әмма алар бәйрәмгә әзерләнү генә иде.

Ә бәйрәм Караярда 30 июньдә булды. Хаҗиәхмәтнең күп санлы токымы: Закировлар, Сәетгалиевлар, Солтановлар, Динисламовлар, Фәтыйховлар, Ильясовлар, Хәйрисламовлар, Әбраровлар һ.б. күпләр җыелды.

Мөселманнарга хас булганча, бәйрәм мәчеттә булудан башланды. Карап торуга зур гына булган Караяр мәчете барлык туганнарны да сыйдыра алмады. Яшь буынга урамда кәтәргә туры килде. Коръән укыганнан соң Хаҗиәхмәт нәселеннән чыккан имам-хатип Галәфим вәгазьләр белән чыгыш ясады.

Җыелган кунаклар Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар истәлегенә куелган обелиск яныннан үтеп китә алмадылар. Анда аларны тарих укытучысы Р.Х.Хәйруллина каршы алды һәм республикабыз, илебез тарихыннан истәлекле өзекләр белән таныштырды, сугышта һәлак булганнарны чәчәкләр салып искә алганнан соң, бәйрәмгә килүчеләр авыл мәдәният йортына юнәлде. Анда Р.Солтанова саф башкорт телендә «шәҗәрә» сүзенең мәгънәсен аңлатты һәм ерак туганнар белән танышулар башланды. Югарыда әйтелгәнчә, Хаҗиәхмәт агачы алты төп ботактан тора, һәр ботакта уллары, кызлары, оныклары һәм туруннарының дистәләрчә исемнәре бар.

Караярда яшәүчеләр һәм кунаклар сәхнәгә чакырылды. Мөхтәрәм картлар һәм яшь сабыйлар, хатыннар һәм ирләр, малайлар һәм кызлар – һәрберсе үзенең зур нәсел токымыннан булуын аңлый иде.

Бәйрәмне алып баручыларның берсе Ә.Х.Сәетгалиева (Хаҗиәхмәтнең турунының оныкасы) Хаҗиәхмәтнең улларын берәмләп күрсәтте һәм җыелучыларга туганлык элемтәсен аңларга ярдәм итте. Җыелган туганнарга концерт номерлары күрсәтелде.

«Чәгән» кызларына (Р.Әрдиева, Бәдретдинова, И.Лотфуллина), шаян бию күрсәткән Р.Әхмәтдиновага һәм И.Әбраровага, җырлары өчен Л.Әюповага, М.Лотфуллинага һәм «Умырзая» ансамбленә (аларны тулы составта ишетәсе килә) рәхмәт.

Бәйрәм соңында, әссәгә бирешмәгән туганнар табынга җыелдылар. Чәй эчү дуслык атмосферасында үтте: кемдер телефон номерлары алышты, кемнәрдер сөйләшеп туялмады, өченчеләре яңа очрашулар билгеләде. Бәйрәм авыл клубыннан әкрен генә өйләргә таралды, ә анда тормыш хакындагы сөйләшүләр бик озак тынмагандыр.

Хаҗиәхмәт нәселе арасында күренекле кешеләр булмаса да (әлегә) без барыбыз да республиканы, илне һәм дөньяны алга итүгә зур өлеш керттек һәм кертәбез.

**Л.Берсонова** (Сәетгалиева).
Тольятти шәһәре.

# Аралашып яшибез

**Соңгы вакытта үз нәселеңне, үз шәҗәрәңне белү кирәклеге турында күп сөйләнелә. Авылларда шәҗәрә бәйрәмнәре, сабантуйлар үткәрелә.**

Мин үз нәсел тамырларымны тикшерүне күп еллар элек үк башлаган идем. Әтием ягыннан 5 буын, әниемнекен 6 буынга тикләм тикшереп, нәсел «агачын» төзедем. Әти яклап карт картәтием Фәүзетдин исемле булган. Аның 2 улы, 3 кызы булуы билгеле. Мал карап; җир эшкәртеп, балык тотып, Байкы буеның Яңа Акбүләк авылында яшәгәннәр. Картәтием Фазлетдин 1939 елда хезмәт армиясенә алынып, шунда үлеп калган. 1931 елда туган әтием Мәгаруф, 8 яшеннән ятим калып, дөньяның ачысын-төчесен татыган, бик зирәк, күңелчәк кеше иде. Озак еллар янгын сүндерүче булып эшләде, күп һөнәрләре бар иде: мич тә салды, балта эшенә дә оста тотынды. Әтиемнең безгә, 5 баласына, дөрес тәрбия биргәнлеген үзебез олыгаеп, балалар үстергәч кенә аңладык. Әтинең хәзер бер туган сеңлесе генә бар ( әни бер, ата башка). Ул әлеге көндә Төрекмәнстанда яши, бер ел элек кунакка кайтып, 40 көн торып китте. Улы Марс әлеге вакытта безгә яшәргә килде.

Карт картәнием Банат исемле булып, бәләкәй буйлы, теремек, уңган хатын булган. Картәнием Аскын районы Кашка авылыннан килен булып төшкән. Тирә-якта аны сүз остасы дип белеләр. Исемдә, Бәдигельямал картәнием безне каникулга чыгу белән, төрле авылларга утырмага йөртә иде. Шунда барлык нәсел-нәсбәт белән таныштыра, юлда барганда «Сак белән Сук» бәетен яттан сөйли, төрле хикәятләр, булган хәлләр турында тезеп бәян итә иде, кешеләр белән дөрес аралашу культурасын да ул биргән дип уйлыймын хәзер. Хәзерге көндә без әтием ягыннан ике туганнан туган 19 кеше, өч туган 22 кеше белән аралашып яшибез.

Әнием яклап нәселебез тагын да калынрак, мәртәбәле, чөнки карт картәтием Иргалә бик ихтирамлы кеше булган, Хәлил авылында яшәгән, икенче карт картәтием Каюм Аскын районы Упканкүл авылыннан, алпавыт булган. Көтү-көтү атлары, сыерлары, җил тегермәне, лавкалары булса да, кешеләргә ягымлы, ярдәмчел булуы белән аерылып торган. Карт картәнием Рәшидә исемле булып, ярлы гаиләдән чыкса да, чиберлеге белән тирә-якта дан тоткан. Каюм картәтием аны икенче хатын итеп алган булган. Аларның 4 кызы, 2 улы булып, Сабрикамал исемлесе Хәлил авылы егете Иргалин Миңлеәхмәткә кияүгә чыккан. Миңлеәхмәт картәтием волость рәисе булып эшләгән. Түрә кешенең буш вакыты сирәк булгандыр, шуңа 4 кызын тәрбияләүдә төп рольне Сабрикамал карт картәнием үтәгән. Миңа 6 яшь тулганда ул үлеп куйды. Минем күз алдында ул тәпәш буйлы, йомры гына, җылы йомшак куллы, ягымлы тавышлы ханым булып басып тора. Шул басынкы холыклы булуы аркасындамы, карт картәтием читтә икенче хатын белән чуалып, соңрак аңа күченеп яши башлый, Үзбәк исемле уллары туа. Иргалин Үзбәк абыем 5 баласы белән Урмияздә яшәде, аралаштык. Әлеге көндә аның балалары Лүзидә, Илшат белән танышбыз. Без әниемнең ике туганнары Гайнанов Муллаян, Галихан, Мөхәмәтҗанов Туктаголлар, аларның балалары белән аралашып яшибез. Үзебезнең ике туганнарыбыз белән гел күрешеп торабыз. Шулардан Гильмалетдинов Ирек, Хаматгалиева Әлфисә, Сафина Рәзинә безнең кебек укытучы булып эшлиләр. Әлеге көндә әни ягыннан 16 ике туганыбыз республиканың төрле районнарында яши, аларның 41 баласы бар, без һәр берсен танып беләбез. Өч туганнардан Гайнановлар, Мөхәмәтҗановлар белән хәл-әхвәл белешеп торабыз.

Шулай итеп, без туганнар, аларның балалары белән үзебезнең балаларны да таныштырабыз, үз нәселеңне, үз тамырларыңны онытмаска кирәклеген төшендерәбез. Башкортлар үзеңнең 7 буыныңны белүне таләп иткән, һәр ыру шәҗәрәсен язып калдыруны төп бурыч итеп исәпләгән. Соңгы елларда безнең якларда да шушы эшне җанландырып җибәрү – бик матур, кирәкле күренеш. Ул туган-тумача арасында дуслыкны, татулыкны ныгыта, ихтирамлы, игътибарлы булырга өйрәтә, туганнар арасында никахлашуга юл куймый, дип уйлыйм.

**З.Галимова.**
Байкыбаш авылы.